ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 15.11.2024 1816 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 31 августындагы 1097/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 августындагы 1097/1 номерлы карары белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә

муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге Нигезләмәнең 2.1. пунктындагы 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«1 нче таблица»

| № п/п | Хезмәткәрләрнеж вазифалары | Вазифаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 27 560 |
| 2 | Оператив кизү торучы | 21 200» |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка  килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева